| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.08.2015** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1710** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында»гы 1553 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районында урнашкан авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортны, урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссия эшчәнлегендә хокук бозуларны бетерү турындагы Зеленодольск шәһәр прокуратурасының 2015 елның 24 июлендәге 1442В-2015 номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясына таянып, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карары кушымтасына «Зеленодольск шәһәре, Загородная ур., 29» 311 пунктны кертергә.
2. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының Зеленодольск муниципаль районының интернет челтәре сайтында һәм «Зеленодольская правда». газетасында урнаштыру юлы белән тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контроль тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзү һәм инфраструктур үстерү буенча Беренче урынбасары Р.О.Котельниковка йөкләргә.

Җитәкче С.Г. Егоров